**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.12.2019 № 1091

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегеннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәк булган товарлар китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Кама Тамагы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 августындагы 763 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товар, эш, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы РФ Хөкүмәте Карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 29.08.2018 ел, № 763 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегеннән

11 километрдан ерак урнашкан  һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче кирәкле товарлар китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Кама Тамагы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"субсидия алучылар-юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучылар-индивидуаль эшкуарлар эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмаска тиеш".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин